МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ
ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.02.2023 Казан шәһәре № 40/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2016 елның 24 мартындагы 49/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатларында, боерам:

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турында” 2016 елның 24 мартындагы 49/2-пр боерыгына (2018 елның 22 мартындагы 57/2-пр боерыгы белән кертелгән үзгәреш белән) (алга таба - Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта “Н.Л. Титов” сүзләрен “Н.Р. Залаков” сүзләренә алыштырырга;

Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турындагы нигезләмәдә:

2.2 пунктның “б” пунктчасында “Татарстан Республикасы Президенты” сүзләрен “Татарстан Республикасы Рәисе” сүзләренә алыштырырга;

3.4.2 пунктның икенче җөмләсендә “кызыксынучы оешмалар” сүзләреннән соң “, шул исәптән коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә “Посейдон” дәүләт мәгълүмат системасын кулланып” сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры
урынбасары - министр М.А. Җәббаров